**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БОЛЬШЕКУЛЬГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422660, с. Большая Кульга ,
ул. Школьная , дом 11

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ОЛЫ КУЛЬГА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422660, Олы Кульга авылы,
Мэктэп урамы, 11 нче йорт,

Тел.: (84361) 29202, факс: (84361) 29202, e-mail: Bklg.Rs@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

06.05.2019 Олы Кульга авылы №13

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Олы Кульга авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм “Җирләү һәм мәет кую эше турында” 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законның 9 маддәсендәге 3 пунктын, 12 маддәсендәге 3 пунктын үтәү йөзеннән, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "2019 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында" 2019 елның 24 гыйнварындагы 32 номерлы карарына, “Татарстан Республикасында “Җирләү һәм мәет кую эше турында” Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында” 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының 3 пунктына таянып КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Олы Кульга авыл җирлегендә мәет кую буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1,2 кушымталар нигезендә 5946,47 сум күләмендә билгеләргә һәм 2019 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә,

2. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә һәм 2019 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Кульга авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Олы Кульга авылы, Мәктәп урамы, 11 йорт; Кече Кульга авылы, Беренче май урамы, 1 йорт; Дон-Урай авылы, Бакча тыкрыгы, 2 йорт; Олы Осиновка авылы, Кооператив урамы, 1 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-

адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Кульга авыл җирлеге
башлыгы вазыйфаларын Башкаручы Е.А.Терентьев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы  Олы Кульга авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2019 елның  6 маендагы
13  номерлы карарына
кушымта  №1

**Татарстан Республикасы**
**Балык Бистәсе муниципаль районының Олы Кульга авыл җирлегендә**
**2019 елның 1 февраленнән  мәет кую буенча хезмәтләрнең**
**гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган**
**хезмәтләрнең бәясе**

| Хезмәтләрнең исеме | Хезмәтләрнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Табут һәм җирләү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү | 1697 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (мәетен) зиратка (крематорийга) күчерү (илтү) | 929 |
| 4. Җирләү (мәетне яндыру,  соңыннан көле салынган урнаны бирү белән) | 3320,47 |
| Барлыгы: | 5946,47 |

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Олы Кульга авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2019 елның 6 маендагы
13 номерлы карарына
кушымта №2

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Кульга авыл җирлегендә ире (хатыны), якын туганнары, башка туганнары яисә мәрхүмнең законлы вәкиле булмаганда яки алар тарафыннан җирләүне гамәлгә ашыру мөмкин булмаганда яисә җирләү бурычын үз өстенә ала торган бүтән зат булмаганда, мәет кую буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча түләүсез нигездә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе**

| Хезмәтләрнең исеме | Хезмәтләрнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 468 |
| 3. Табут һәм җирләү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү | 1229 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (мәетен) зиратка алып бару (илтү) | 929 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3320,47 |
| Барлыгы | 5946,47 |